ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**25.07.2016 г.**

.Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 1940**

Җир эшләре башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законга таянып,, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 28 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән, «муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 28.03.2011 ел, № 437 карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 17.09.2015 ел, №1936 карары белән расланган җир эшләре башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1.1. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләпләр исеме» графасындагы 2.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә гариза бирүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына карата таләпләр, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларның үтемлелеген тәэмин итүгә, инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү хезмәтләре»

1.2. 2.14 пунктын «стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында яңа редакциядә бәян итәргә: «муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм биналарда, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазларда, мәгълүмат стендларында башкарыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керүе тәэмин ителә (бинага керү һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү уңайлы).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикле булган очракта да урнаштырыла».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыруны тәэмин итәргә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе
вазифаларын башкаручы А. В. Старостин